КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 октябрь г.Казань № 1345

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 29 сентябрь, 925 нче карары белән расланган Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2022 ел, 2 декабрь, 1276 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 март, 281 нче; 2023 ел, 18 июль, 859 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Үзйөрешле машиналар һәм
техниканың башка төрләре,
аттракционнарның техник
торышы һәм аларны
эксплуатацияләү өлкәсендә
төбәк дәүләт күзәтчелеге
турындагы нигезләмәгә
3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 24 октябрь, 1345 нче
карары редакциясендә)

Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Бер календарь ел дәвамында закон көченә кергән мәҗбүри таләпләрне бозган өчен юридик затка, индивидуаль эшмәкәргә яки аларның вазыйфаи затларына административ җәза билгеләү турында 3 һәм аннан күбрәк карар булу.

2. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышын күзәтү идарәсендә контрольдә тотылучы затның теркәү исәбендә торган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 13 ноябрендәге 1013 номерлы карары белән расланган Үзйөрешле машиналарга һәм техниканың башка төрләренә техник тикшерүне үткәрү кагыйдәләре нигезендә техник тикшерү узган үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләренең гомуми саныннан 50 проценттан артык үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре булу.

3. Гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерелгән, билгеле бер контрольдә тотылучы зат тарафыннан эксплуатация нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук үзйөрешле машиналарны һәм техниканың башка төрләрен имин эксплуатацияләү өлкәсендә мәҗбүри таләпләр бозылу ачыкланган юл-транспорт һәлакәтләрен кылу факты (фактлары) турында мәгълүмат булу.

______________________________